Хатыйп Миңнегулов

# 2011 елда «Казан утлары»

Кемгә, ничектер, әмма миңа, өлкәнәя барган саен, вакыт агышы тизлеген арттырган кебек: әле менә яңа гына XXI гасырга аяк баскан идек, инде аның да уннан бер өлешен узып киттек; әле генә капкасын ачып кергән 2011 ел да инде тарихта калды. Яңа 2012 елны да тәүлекләп, атналап ваклый башладык. Табигый вакыт агышы, никадәр тырышсаң да, һич туктамый, аккан су кебек, ага да ага, ага да ага. Әмма тәнендә жаны булган адәм баласы рәхимсез вакыт агышын да җиңәрлек могҗизаи көчкә ия, — ул да булса — хәтер, фикерләү. Алар ярдәмендә кеше үткәнгә дә, киләчәккә дә сәяхәт итә, вакытны акрынайтырга да, тизләтергә дә, фикри-хисси яктан тикшерү объектына да әйләндерә ала.

Узып киткән 2011 ел һәм галәми, һәм милли масштабта шактый катлаулы һәм каршылыклы ел булды. Татар рухи мәгыйшәтендә без куаныч-шатлыкларга караганда, күңелсезлекләр белән ешрак очраштык. Милли мәгариф, милли мәдәният кысылганнан-кысыла бара. Ассимиляция, телне югалту башка төбәкләрдә генә түгел, Татарстанда һәм Башкортостанда да гадәти күренешкә әйләнде. Без гасырлар буе зыялыларыбыз көрәшеп килгән «гафләт» (ваемсызлык; битарафлык; мәсләксезлек) йокысында. Сүз белән генә түгел, күсәк белән орсаң да уянмаслык дәрәҗәдә. Күптән түгел генә 2010 елда үткәрелгән җанисәп мәгълүматларын игълан иттеләр. Соңгы сигез елда Рәчәйдә татарлар саны 240 меңгә кимегән. Бу бит коточкыч хәл. (Югыйсә, бу елларда сугышлар да, ачлык та булмады.) Әгәр дә болай барсак, Гаяз Исхакый әйткән инкыйраз чоңгылы да ерак калмаска мөмкин. Дистә елдан да ким вакытта чирек миллионга, уртача тулы бер халык санынча кимегәнбез. Ә без бу хакта уйламыйбыз да, чаң да сукмыйбыз, мактануны, шапырынуны, кәеф-сафа коруны дәвам итәбез.Мондый хәлнең сәбәпләре нәрсәдә, алга таба нишләргә — бу сораулар хәтта куелмый да. Әле хәзергә җанисәп материалларның телләр турындагы өлеше игълан ителмәгән. 5,31

миллион татарның күпмесе үз туган телен белә? Анда да безне, мөгаен, күңелсез, хәтта аянычлы рәсми мәгълүматлар көтәдер. Болар хакында, шәт, матбугатта, шул исәптән «Казан утлары» журналында җитди, аналитик чыгышлар булыр дип өметләнәм.

Шунысы гыйбрәтле: кыен рухи-социаль вәзгыятьтә дә милли мәнфәгатьләр файдасына фидакарьләрчә аерым эш-гамәлләр кылына. Татарча укучылар даирәсе тарая барса да, китаплар, гәҗит-журналлар басыла, аз булса да әдәбиятка, журналистикага сәләтле каләм әһелләре килеп тора. Мондый хәрәкәт «Казан утлары» мисалында да ачык күренә. Мәгълүм ки, бу мәҗмуга — татар дөньясында чыгып килүче иң өлкән журналларның берсе. Аның мәйданга килүенә быел 90 ел тула. Шушы вакыт эчендә ул чын мәгънәсендә татар тарихының, рухи тормышының көзгесе, елъязмасы, штабы булды. Бу мәҗмуга татар мәгыйшәтенең үзенә күрә бер символына, таяныч ноктасына да әверелде.

Миңа соңгы елларда «Казан утлары» хакында төрле киңәшмә-җыелышларда, матбугат, радио аша чыгышлар ясарга туры килә. Мәсәлән, аның 2009, 2010 елгы саннары турында «Мәдәни җомга» сәхифәләрендә дә мәкаләләрем дөнья күрде («Әдәби хәрәкәтебезнең көзгесе».— 19.02.2010; «Әдәбиятебезнең мәркәзи мөнбәре». — 18. 02. 2011). Шул традициягә тугры калып, «Казан утлары»ның 2011 елгы саннары хакында кайбер фикер-күзәтүләремне, аерым әсәрләр һәм авторлар турындагы уйлануларымны укучыларга җиткерергә җөрьәт итәм. Журнал, билгеле булганча, шактый күләмле (еллык саннарының гомуми битләр саны 2300 дән артып китә), андагы материаллар да төрледән-төрле (роман-бәяннар саны гына дистәгә җитә). Шуңа күрә бу язма һич тә тулылыкка, киңлеккә дәгъва итми.

2011 ел тарихка «Тукай елы» буларак кереп калды. Бу сәнәдә без бөек шагыйребезнең 125 еллыгын чын мәгънәсендә исеменә җисеме туры килешле югарылыкта, киң планда, колачлы рәвештә уздыруга ирештек. «Казан утлары» да бу вакыйга-чараларның үзәгендә булды. Аның сәхифәләрендә

Тукайга мөнәсәбәтле шактый гына язмалар дөнья күрде. Болар арасында аеруча Рабит Батулла һәм Ркаил Зәйдулла әсәрләре дикъкатькә лаек.

Мәгълүм ки, бөек шагыйрьне әдәбиятта гәүдәләндерүнең озын-озак тарихы бар. Бигрәк тә Әхмәт Фәйзинең һәм Рөстәм Вәлиевнең романнары, Ибраһим Нуруллинның китаплары билгеле.

Югарыда телгә алынган һәр ике автор да, үз элгәрләренең әдәби-эстетик тәҗрибәсен файдаланып, бүгенге укучыларның рухи ихтыяҗларына җавап бирерлек әсәрләр тудырганнар.

Р. Батулла үзенең «Апуш-Тукай» язмасын «кыйсса» дип атаган. Чыннан да бөек шагыйрьнең чынбарлыктагы тормышы һәм аның әсәрдә гәүдәләнеше үзенең драматизмы, фаҗигаи-героик (каһармани) характеры белән элеккеге дастан-кыйссаларны хәтерләтерлек. Фәнни яктан караганда исә Р. Батулла язмасы тарихи-биографик роман жанрына туры килә. Дөрес, анда автор фантазиясе белән тудырылган вакыйга-күренешләр дә шактый. Әмма алар реаль чынбарлык, шагыйрь тормышындагы төп факт-мәгълүматлар белән табигый яраштырып, тарихи хакыйкатькә тугрылык саклап бирелгәннәр.

Р. Батулла романында бөек шагыйрьнең тууыннан алып үлеменә кадәрге тормышы гәүдәләнеш тапкан. Әсәр дулкынландыра, урыны белән хәтта күздән яшьләр китерә, авторның талантын, сүз остасы икәнлеген янә бер мәртәбә раслый. Романда холык-характерлар тудыруның, рухи халәтне тасвирлауның матур үрнәкләре бар. Автор кечкенә, истигъдадлы Апушның бөек Тукай булып өлгерүен укучыны ышандырырлык картина-күренешләрләрдә сурәтли алган. Әсәрдә табигатьне, тормыш-көнкүрешне, мохит-даирәне, рухи-дини кыйммәтләрне тасвирлауга да зур урын бирелгән. Алар ярдәмендә автор Тукайның чын мәгънәсендә татар яшәеше белән табигый берегүен, татар җанының мөһим бер җисеме булып үсүен ассызыклый. Р. Батулла, тарихи чынбарлыкка тугры калып, Тукай даирәсе кешеләрен, ул аралашкан затларны тасвирлауга да җитди игътибар итә. Нигездә, аларның исемнәрен, кылган гамәлләрен дә искә төшерә. Бу төр

шәхесләр арасында, туган-тумачаларыннан тыш, Мотыйгулла хәзрәт һәм аның улы Камил Мотыйгый, Габдулла Кариев, Фатих Әмирхан, Хөсәен Ямашев, Зәйтүнә туташ һәм башка билгеле затлар да бар. Әсәрнең, гомумән, Тукайны гына түгел, ә шул чор татар мәгыйшәтен, рухын танып-белү ягыннан да әһәмияте зур. Миңа шәхсән шагыйрьнең Казангача чор тормышын яктырткан өлешләре күбрәк ошады. Казан дәверен тагын да тулырак, үтемлерәк итеп тасвирлау мөмкинлекләре әле калган кебек.

Шунысын да әйтик: Рабит Батулла соңгы елларда үзенең иҗади активлыгын тагын да арттырды. Аның, мәсәлән, узган ел гына да калын-калын китаплары дөнья күрде. Аларның «Шайтан таягы» дип исемләнгән икенче томында «Апуш-Тукай» кыйссасы һәм Рудольф Нуриев турындагы «Бию җене кагылган егет» исемле 400 битлек романы да урын алган.

2010 елда «Казан утлары»нда 3 драма әсәре басылса, быел аларның саны — ике. Шуларның берсе Ркаил Зәйдулланың Тукайга багышланган «Шул булды эш... (И минем яктыртучым!)» дип исемләнгән язмасы (12 нче сан). Р. Батулла романыннан үзгә буларак, биредә бөек шагыйрь белән Зәйтүнә мөнәсәбәтләре үзәккә куелган. Әмма бу гыйбрәтле мәхәббәт тарихы да шул чор, аның аерым затлары, каләм әһелләре (Фатих, Сәгыйт, Кәбир, Вафа...) белән бәйләнештә тасвирланган. Автор Зәйтүнә-Тукай мәхәббәтенең бөеклеген, фаҗигалелеген, үзенчәлеген дә яктырта алган. Кечерәк кенә күләмле бу драмага хис-кичерешләрнең табигыйлеге, композицион бөтенлек, сәнгати логикалылык хас. Автор кулланган алымнар, шартлы образлар ("Кара җиләнле — шагыйрьнең тәкъдире»; «Күн»...) һәм чаралар да, лексикасы да (төрле вакыт яссылыкларын кушып җибәрү, кесә телефоннарыннан шалтырату, SMSлар җибәрү...) укучы-тамашачы тарафыннан табигый кабул ителә.

Р. Батулла кебек, Р. Зәйдулла да, рәсми тел белән әйтсәк, төрле фронтларда нәтиҗәле хезмәт кыла. 50 яшен ул күренекле шагыйрь буларак кына түгел, ә оригиналь фикерләүче драматург; прозаик, публицист сыйфатында да каршылый. (Ходай Тәгалә аңа киләчәктә исәнлек бирсен,

илһам дулкыннарын юлдаш итсен!)

Билгеле булганча, XV йөзнең урталарында Алтын Урда таркалып, аның нигезендә Казан, Кырым, Әстерхан, Олы Урда, Себер, Касыйм, Нугай ханлыклары төзелә. Аларның төп халкын татарлар тәшкил итә һәм шуңа мөнәсәбәттә бу илләр еш кына татар мәмләкәтләре дип йөртелә. Болар арасында сәяси һәм хәрби беренчелекне Кырым ханлыгы тотса, мәдәни, рухи һәм иҗтимагый беренчелек Казан мәмләкәтендә була. Ул, бер яктан, Болгар, Хәзәр кебек элгәрге төрки-татар дәүләтләренең дәвамчысы була [(Бу хакта Шәрифинең «Зафәрнамәи вилаяти Казан» әсәрендә дә (1550)] искәртелә. Икенче яктан, Казан ханлыгы Алтын Урда дәүләтенең турыдан-туры варисы да. Аны нигезләүче Олуг Мөхәммәднең Сарайдагы соңгы ханнарның берсе булуы, нәсел шәҗәрәсенең Чыңгызга барып тоташуы да күп нәрсә хакында сөйли. Нәкъ менә шуңа күрә дә Казан ханлыгы татар дәүләтчелек тарихының, милли язмышының данлы да, фаҗигале дә бер җисеме, күп төрле мәсьәләләр бергә укмашкан буыны, ярасы ачык калган бер җәрәхәте булып тора. Бу ханлык язмышында бүгенге көнгә дә аваздаш яклар шактый. Юкка гына Мәскәү үзенең колониаль сәясәтен, империя төзүен Казанны яулап алудан башламый. Урыс профессоры М. Худяковның мәшһүр хезмәтендә, атаклы Г. Исхакыйның «Олуг Мөхәммәд» драмасында һәм кайбер башка тарихи, әдәби язмаларда Казан ханлыгына зур урын бирелүе юкка гына түгел. Әмма шулай да бу мәмләкәтнең эчке тормышы, халыкара мөнәсәбәтләре, иң мөһиме — аның үзәгендә торган затлар әдәбиятта һәм сәнгатьтә һаман да тиешенчә яктыртылыш тапмаган. Тормыш һәм әдәби тәҗрибәсе бай булган, шактый өлкән яшьтәге Марат Әмирхановның (аңа алдагы елда, Алла боерса, 80 яшь тулачак) Казан ханлыгы тематикасына ныклап керешүе үзе үк бик мәгънәле. Ул соңгы 4 елда «Казан утлары»нда берсеннән-берсе саллы өч әсәрен бастырды: «Үрбәт ханәкә гыйшкы» (2008. — 4—7 нче саннар), «Гәүһәршад» (2009. – 6—7 нче саннар) һәм «Әлвидаг» (2011. — 11 нче сан). Боларны автор үзе «тарихи бәян» дип атаган. Әмма алар һәм эчтәлекләре, һәм корылышлары белән тарихи роман жанрына туры

килә. Бу әсәрдәге вакыйга-хәлләр бер үк чорда — XVI йөзнең беренче яртысында һәм урталарында бара. Аерым геройлар да уртак һәм бер-берсенә мөнәсәбәтле (Мөхәммәд Әмин, Гәүһәршад, Сөембикә, Мөхәммәдьяр һ.б.). Шуңа күрә бу өч романны трилогия дип та атарга мөмкин. Автор тарихи чынбарлыкны тирәнтен тоеп, факт-мәгълүматларны ныклап өйрәнеп яза. Ул бу дәвернең вакыйга-хәлләрендә судагы балык кебек эш итә. Әдип аеруча хөкемдарларның, тарихи шәхесләрнең эчке психологиясен, теләк-омтылышларын тасвирлауда, характер-холыкларын яктыртуда уңышлы эшли. Ул тудырган Үрбәт ханәкә, Гәүһәршад, Сөембикә — һәрберсе кабатланмас, үзенчәлекле образ буларак күзаллана. Трилогиянең тел-стиле бай, сыгылмалы.

Узган ел дөнья күргән «Әлвидаг» әсәренең үзәгендә татарның бөек кызы — Сөембикә, аның иленнән аерылуы, әсирлек газаплары. Бәянның «Әлвидаг», ягъни аерылышу, бәхилләшү дип аталуы да шуның белән аңлатыла. Трилогиянең өченче кисәген (китабын) тәшкил итүче бәянның корылышы да үзенчәлекле. Автор аның бүлекләрен юкка гына «кыйсса» дип атамаган. Язма үзенең төзелеш-структурасы белән «кысалы (каймалы) кыйсса» жанрындагы «1001 кичә», «1001 сәхәр» кебек китапларны хәтерләтә. Анда төп, оештыручы сюжет сызыгын Татли һәм Марсель мөнәсәбәтләренә, эш-гамәлләренә нисбәтле вакыйга-хәлләр тәшкил итә. Аның беренчесе — урыслашкан татар нәселенең мөһаҗирлеккә киткән бер вәкиле — княгиня Татьяна Дюпон (Татли), ә икенчесе — татар археологы Марсель. Ул үзенең нәсел тамырларын барларга, Сөембикә тарихын өйрәнергә килгән Татлине озатып йөри. Алар бергәләп Әстерхан, Мәскәү, Касыйм, Санкт-Петербург шәһәрләренә баралар, күп төрле мәгълүматлар туплыйлар. Әсәрдәге икенче төп сюжетта Марсель-Татли мөнәсәбәтләренә, табышларына нисбәтле вакыйга-хәлләр бәян ителә. Вакытның «Әлвидаг»та бу рәвешле ике яссылыкта бирелүе язманың мавыктыру көчен, эстетик тәэсирен арттыруга ярдәм иткән. Әсәрдә Сөембикә төрле планда тасвирлана: ул атасының яраткан кызы да, хан хатыны һәм хөкемдар да, ана да. Әмма

аларның һәммәсен чибәр һәм уңган, зиһенле һәм кешелекле хатын-кыз образы берләштереп тора. Автор Сөембикәгә каршы кешеләрне дә, шул исәптән Иван патшаны, аның якыннарын да тоташтан каралтмыйча, төрле буяулар белән тасвирларга омтыла.

Марат Әмирхановның триологиясе — татар прозасының соңгы еллардагы зур казанышы. Ул, һичшиксез, Тукай бүләгенә лаеклы әсәр.

Әгәр дә алда телгә алынган әсәрләрнең үзәгендә тарихи затлар, күренекле шәхесләр булса, Сәгыйт Лашманчы романының (12 нче сан) төп каһарманнары авылның гади хезмәт кешеләре. Биредәге вакыйга-хәлләр дә чагыштырмача соңрак чорга — узган гасырның 30—80 елларына карый. Әсәр карт белән карчыкның тормышын сурәтләү белән башланып китә. Йорт хуҗасы Хабул (Хабулла) паралич сугып «аяксыз калган», инде өченче җәй урын өстендә. Сара карчык ирен дә, хуҗалыктагы тавык чүпләп тә бетерә алмаслык эшләрне дә карый, намаз да укый. Көннәрнең берендә хуҗабикәнең тамагы авырта башлый. Анда яман чир табалар, операциягә барырга, ирен картлар йортына бирергә тәкъдим итәләр. Сара карчык беркая да бармаска карар кыла. Шушындый фонда ир белән хатынның үткәннәренә экскурс ясала. Аларның яшьлеге, гаилә коруы, колхозда эшләүләре, башларыннан кичкән куанычлы, фаҗигале хәлләр бәян ителә. Хабул сугышка алына, ракетчик була, әсирлеккә эләгә, күп төрле газаплар күрә. Алман тоткынлыгыннан котылса да, үз илендә төрле тикшерүләргә, кимсетелүләргә дучар ителә. Әсирлектә вакытта Хабул бераз вакыт бер алман баронының утарында хезмәтче булып тора. Германиянең җиңелүе алдыннан хуҗа агуланып үлә. Хабул шул вакытта агу салынган ике кечкенә пакетны ала, үзе белән йөртеп, авылга да алып кайта. Карт белән карчык берничә көннән соң «алман күчтәнәчен» кабып, үләргә карар кылалар. Шушындый гайре табигый халәттә үткәннәрне искә төшерү, төрле вакыт яссылыкларының үзара кушылып китүе әсәрдәге киеренкелекне, фаҗигаи драматизмны тагын да көчәйтә. Сара һәм Хабул язмышы укучыны уйландыра, хисләндерә. Аларның күргән-кичергәннәрендә билгеле бер

дәрәҗәдә ил, халык язмышы да чагылыш тапкан.

Фаҗигаи дулкынга көйләнгән вакыйга-хәлләр ахыр чиктә үзгәреп китә: роман омтимистик рухта төгәлләнә. Үлем көтеп яткан карт белән карчыкның озак еллар югалып торган уллары Давыт кайта; аның сый-хөрмәте, дәва-дарулары әти-әнисенә җиңеллек китерә, яшәү өметен һәм дәртен кузгата. Пәйгамбәр исемен йөртүче улларының игътибары, күчтәнәчләре «алман күчтәнәче»ннән баш тартуга, аны гаепләүгә китерә.

Романның авторы Сәгыйт Хафизов — Гаяз Исхакыйның ата-бабаларын биргән атаклы Лашман төбәгеннән. Заманында ул Казан дәүләт университетында укыды, профессор Ибраһим Нуруллин җитәкчелегендә аспирантура узып, XIX йөз татар прозасы буенча кандидатлык диссертациясе яклады. Аннан озак еллар буе Уфадагы дүләт университетында һәм педагогия институтында әдәбият укытты. Әдәбият галиме, тәнкыйтьче буларак танылды, хикәя-бәяннар язгалады. Инде менә романы дөнья күрде. Ул күп көч түгеп, тырышып язылган, тел-стиле дә бай. «Алман күчтәнәче» укыла, уйландыра. Аны узган елгы татар прозасындагы уңышлы әсәрләрнең берсе дип санарга мөмкин.

Әдәби хәрәкәт, — гәрчә аны аерым, мөстәкыйль әсәрләр барлыкка китерсә дә, чагыштырмача бердәм, дәвамлы процесс. Ә инде «Казан утлары», язма мәдәниятебезнең төп журналы буларак, шул хәрәкәтнең көзгесе, мәркәзи мөнбәре. Шуңа күрә аның елларга, айларга бүленешендә билгеле бер шартлылык та бар. Чынбарлыкка нисбәтле дәвамчанлык, чагыштырмача бердәмлек журналның төзелеш-структурасында да, тел-стилендә дә, эчтәлек тә һәм авторларында да күзгә ташлана. Аерым язмалар хәтта бер елдан икенчесенә дә күчеп, дәвам иттерелә. Альберт Хәсәновның «Данәгөл» романы «Казан утлары»ның 2010 елгы 7—8 саннарында дөнья күрде. Татар әдәбияты өчен чагыштырмача яңа вакыйга-хәлләрне, геройларны үз эченә алган бу әсәр укучылар тарафыннан җылы кабул ителде, матбугатта да уңай бәяләнде. Инде менә 2011 елда «Данәгөл» романының икенче китабы журнал битләрендә басылып чыкты (7—8 нче

саннар).

Әгәр дә әсәрнең тәүге өлешендә «Сергей Киров» крейсеры белән Франциянең Марсель каласына килгән Таһирның биредә яшәүче Данәгөл исемле татар кызы — рәссамы — белән танышуы, аңа өйләнүе тасвир ителсә, икенче китапта егетнең никахлы хатыны яныннан киткәннән соңгы хәл-әхвәлләре сурәтләнә. Илгә кайткач, Таһир демобилизацияләнә: чирәм җирләрдә, урман кисүдә, сәүдә корабларында эшли; өч елдан артык пиратлар кулында тоткынлыкта да газап чигә. Аннан котылгач, илгә «хыянәт итүдә» нахакка гаепләнеп, 5 ел төрмәдә дә утыра. Кеше хокукларын саклаучылар тырышлыгы белән ул, ниһаять, зинданнан азат ителә. 19 елдан соң Данәгөл белән Таһир янә кавыша. Аларның инде бу вакытта Галимҗан исемле уллары үсеп җитә. Данәгөл — тәрбияле, милли җанлы татар кызы. Әмма ул — чит ил кешесе. Совет чорында андый затлар белән мөнәсәбәткә керү, әлбәттә, каты гаепләнә. Таһир да чит мәмләкәт кешеләренә мәхәббәте өчен төрле газапларга дучар ителә. Данәгөл — тормышта үз урынын тапкан талантлы зат, халыкара билгеле рәссам. Ул сөйгәненә, никахлы иренә тугрылык саклый, аны эзләү, кайтару юнәлешендә эш-гамәлләр кыла.

Шулай да «Данәгөл» романының икенче китабы беренчесенә караганда бераз кайтышрак чыккан. Таһирның Оксанага өйләнеп алуы, корабта йөргәндә диңгезгә ташлануы әдәби-эстетик һәм психологик яктан бик дәлилләнеп җитми. Диңгез пиратлары кулындагы әсирлеге дә элеккеге маҗаралы кыйссаларны хәтерләтә. Старпом Рудольф Рюкзакның Таһирга сөйләгән мәхәббәт тарихлары да озынга китә, укучыларның игътибарын төп геройлар язмышыннан читкәрәк тарта башлый. Әмма аерым кимчелекләр, бәхәсле яклар булуга да карамастан, А. Хәсәнов романы татар әдәбиятына яңа сәхифә өсти. Ул тудырган Данәгол образы үзенең бөтенлеге, таланты, кабатланмас булуы белән күңелдә якты эзләр калдыра.

Әгәр дә элеккеге дәвер укучылары шигърияткә өстенлек бирсә, хәзер исә гавам игътибарын чәчмә әсәрләр күбрәк җәлеп итә. Журнал сәхифәләрендә дә алар төп урынны били. Шуңа мөнәсәбәттә бу язмада да

проза күз уңында торды. Әлбәттә, «Казан утлары»ның узган елгы саннарында чәчмә әсәрләр без телгә алганнар белән чикләнми. Алар арасында уңышлы гына иҗат ителгән башка язмалар да бар. Мәсәлән, Р. Мөхәммәдиевнең «Прәннекле төшләрем» хикәясе (7 нче сан) бала психологиясен тирәнтен тоеп язылган. Т. Галиуллинның «Китек көзге» бәяне (9 нчы сан) — деталь-сурәтләргә байлыгы (хәтта урыны белән алар артык күбәеп, динамиканы да киметә) белән игътибарны җәлеп итә. Әсәрдәге Габделбәр образы да кызыклы чыккан. Ул башкаручы («исполнитель»), йомышны үтәүче, күндәм, әмма үз мәнфәгатен һич тә онытмый. Мондый типлар тормышыбызда да еш очрап тора.

Әлбәттә, журналдагы чәчмә әсәрләр һәм гомумән язмалар ал да гөл рәвешендә генә күзалланмасын. Аларда һәм тел-стиль, һәм эчтәлек-сәнгати җәһәттән аерым бәхәсле яклар, җитешсезлекләр дә күзгә ташлана. Урыны белән күпсүзлелек, бик билгеле әйберләр һәм күренешләр хакында артык киңәеп язу күзәтелә. (Кызганыч ки, мондый хосусият безнең язмалар өчен чит түгел). Телебездәге сүзләрне онытып, чит тел алынмаларын куллану да очрый. Мәсәлән, «Данәгөл» авторы Штраусны «вальслар гение» дип атый (8 нче сан, 63 б.). Югыйсә, бит телебездә даһи дигән бик матур сүз бар. Аерым фактларны, әйберләрне, күренешләрне куллануда кайчак тарихи хакыйкать тиешенчә искә алынмый. «Алман күчтәнәче» романында «почта аша Казаннан бер кап китап» килүе, арада «Мөхәммәдьяр исемле борынгы шагыйрьнең «Төхфәи мәрдан» исемле әсәре дә булуы» искәртелә. Әле яңа гына кияүгә чыккан Сара бу китапны бирелеп укый (12 нче сан, 40 б.). Бу вакыйга узган гасырның 30 нчы елларында бара. Чынлыкта исә Мөхәммәдьярның тәүге басма китабы 1966 елда гына дөнья күрде. КамАЗда тәүге автомобиль 1976 елның 16 февралендә конвейердан төшә. «Данәгөл»дә исә Таһир узган гасыр урталарында ук, бәхәсләшеп, «Командир» сәгатен КамАЗ астына салып карый, әмма аңа «пычагым» да булмый: «тек-тек» текелдәвен дәвам итә (7 нче сан, 96 б.). «Әлвидаг»та «1554 елда Әстерхан тез чүкте» диелә (11 нче сан, 65 б.). Бу ханлык исә ике елдан соң гына бетерелә.

Узган еллардагы кебек, әдәби процесска нисбәтән, журнал шигърияткә дә даими рәвештә урын биреп бара. Андагы авторларның төп өлешен, нигездә, бүген актив иҗат итүче шагыйрьләр алып тора. Сирәгрәк кенә булса да Башкортостанда яшәүче милләттәшләребез дә (Рим Идиятуллин, Мөнир Вафин, Фәрит Суфияров, Илдус Фазлетдинов...) журнал сәхифәләрендә чыгыш ясый. «Казан утлары» гадәттәгечә яшь шагыйрьләрне һәм гомумән яшь авторларны да читтә калдырмый. Журналдагы шигъри әсәрләрнең күпчелеге шактый кызыклы, үзенчәлекле. Аларның берсен телгә алып, икенчесен калдыру да кыен. Шулай да «Казан утлары»нда чыгыш ясаган берничә авторның шигырьләре хакында шәхси фикер-тәэсирләремне белдереп китәм.

Марсель Галиевнең «Тәхет куйган халык — бәхет жуя» дип исемләнгән шигъри бәйләме (11 нче сан,), аталышыннан ук күренгәнчә, тирән мәгънәле, халык язмышы белән тыгыз бәйләнешле. Мәсәлән, биредәге «Бөек дала — Ана-Ил» шигыренең һәр юлы, һәр строфасы рухи, милли фаҗига һәм үкенеч хисләре белән сугарылган.

... Алтын Урда.
Дөнья хозурында
Кайда синең сөрмә-алтыннарың?
Хач имезгән күпме гөмбәзләрдә
Күрәм аның зәһәр ялтыравын...

Милли тематика икенче бер азнакайлы (10 нчы сан) Нур Әхмәдиев шигыръләренең дә үзәгендә. Аның «Бәгырьдә бар — ташлар» циклында татар язмышы төрле ракурсларда яктыртыла. Коточкыч югалтулар, газаплы көннәр булган. Әмма халык исән калган, яши.

... Татарларым бакыр, көмеш түгел,
Борынгыдан затлы алтын ул.
Ничә тапкыр кылыч аша үтеп
Исән калган газиз халкым ул!

Нур Әхмәдиев үзенә хас юмор хисен хәтта бик җитди шигырьләрендә

дә сиздереп куя:

...Тынычландык, мисле алаша без,

Хөкүмәтне эчтән эттәй сүгеп,

Хатын белән тәмләп талашабыз...

Очраклымы, юкмы, — анысын белмим, әмма янә бер азнакайлының шигырьләре күңелне җәлеп итте. Ул — Илдус Гыйлаҗев. Аның ике дистә парчасы журналның беренче санында дөнья күргән. Ул шигырьләр, гәрчә кыска-кыска булсалар да, бик мәгънәле. Аларда халкыбыз язмышы, аның теләк-өметләре, моң-зарлары гәүдәләнеш тапкан. Шагыйрьнең «Баскыннар кагыйдәсе» парчасы сәхнәләрдән, радио-телевидениедән кат-кат яңгыратуны көтеп тора.

2011 ел берничә күренекле шагыйрьнең (Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Гарифҗан Мөхәммәтшин һ.б.) түгәрәк даталары да иде. Аларның иҗатларында да телгә алып сөйләрлек шигырьләр шактый. Мәсәлән, Р. Гаташ, Бабичның «Исемнәр бакчасында» циклы үрнәгендә милләттәшләребезгә багышлап робагыйлар (3 нче сан) иҗат иткән. Алар арасында мәшһүр Миркасыйм Госманов та (аның юклыгы хәзер гыйльми-милли тормышта шундый нык сиздерә), Америкада гомер кичерүче Вил Мирзаянов һәм Мәсгудә ханым да, Төркиядә төпләнгән Чулпан Зариф та бар.

2011 елда «Казан утлары»ның «Сатирик әсәрләр конкурсы» оештыруы да журнал эчтәлеген баетуга һәм төрләндерүгә мөмкинлек бирде. Анда өч дистәгә якын автор үзләренең чәчмә, шигъри, драма әсәрләре белән катнашты. Яшь иҗат көчләрен тәрбияләүне һәм үстерүне, журнал укучыларның аудиториясен киңәйтүне күздә тоткан «Ак җилкән» рубрикасы да камилләшә бара.

«Казан утлары» традиция нигезендә, әдәби әсәрләрдән тыш, публицистик, әдәби тәнкыйть, сәнгать, тарих, фән һәм кайбер башка тармакларны да күз уңында тота. Мәгълүм булганча, 2010 елның 25 ноябрендә Польшаның Гданьск каласында җайдак татар гаскәриенә мәһабәт һәйкәл куелды. Аны рәсми ачу тантанасында Польша җитәкчелеге, күп санлы кунаклар катнашты.

Ил президенты Бронислав Коморовский үзенең чыгышында татарларның батырлыгын, хәрби осталыкларын, намуслылыгын, ватанпәрвәрлеген кат-кат искәртте. Журналның беренче санында Гданьск тантанасына мөнәсәбәтле фотоматериалларның һәм Польша җитәкчесенең чыгышы бирелү бик тә урынлы булды.

Удмуртия Татар иҗтимагый үзәге башлыкларының берсе Мәсгут Гаратуев чыгышы (4 нче сан) сәяси яңгырашы, милләт мәнфәгатьләрен кыю яклавы белән аерылып тора. Индус Таһировның татар тарихын яктыртуга багышланган мәкаләсе дә (5 нче сан) бик кирәкле һәм файдалы. Тәлгат Насыйровның «Татар матбугатының авыр хәле» язмасында (2 нче сан) 30 нчы еллар татар матбугатына анализ ясала. Мәгълүм булганча, XX йөз башында гына түгел, ә Октябрь инкыйлабыннан соңгы елларда да илебезнең милләттәшләребез яшәгән төбәкләрендә (Себер, Ерак Көнчыгыш, Кавказ, Донбасс һ.б.) күп татарча гәҗит-журналлар чыгып килә (Мәскәүдә генә дә — 9). Әмма аларның йөздән артыгы 30 нчы елларда ук Мәскәү әмере белән ябыла. Димәк, татар теленә, татар басма сүзенә каршы бүген дә бара торган сәясәтнең тамырлары 30 нчы елларга ук барып тоташа икән.

Шулай да әле журналда үткен сәяси публицистик язмалар, милли яшәешнең гыйбрәтле сәхифәләрен яктырткан чыгышлар сирәгрәк күренә. Нишләптер, узган ел Айдар Хәлим һәм Фәүзия Бәйрәмова кебек тәҗрибәле әдип-публицистлар да мәҗмуга битләрендә үзләренең ялкынлы сүзләрен укучыларга ишеттерми калдылар.

«Казан утлары» һәр санында диярлек тәнкыйть һәм әдәбият тарихы турында материаллар биреп бара. 2011 елның 20 маенда Татарстан язучыларының татар балалар әдәбиятын тикшерүгә багышланган гомуми җыелыш-конференциясе булган иде. Андагы төп чыгышларны укучыларга җиткереп, журнал саваплы эш башкарган (8 нче сан). 2011 елда күп санлы юбилейлар булып узды. Шул уңай белән «Казан утлары» кызыклы гына әдәби-тәнкыйди язмалар бастырып чыгарды. Болар арасында аеруча Т. Галиуллинның Р. Харис (5 нче сан), Ф. Хәсәнованың Р. Гаташ (3 нче сан) иҗатына багыш-

ланган мәкаләләре гыйльми-эстетик камиллекләре белән аерылып тора.

Шунысы мөһим: хәзерге әдәбият фәнендә һәм тәнкыйтендә сүз сәнгатен фәлсәфи, теоретик яссылыкта яктырту тенденциясе көчәеп бара. Алсу Шәмсутованың «Алдымда — чикле чиксезлек» мәкаләсе (11 нче сан) — шуның ачык бер мисалы. Ул уку, кабул итү өчен авыррак стиль белән язылган. Әмма анда Рәмис Аймәтнең шигъри дөньясы, образлы фикерләү үзенчәлекләре шактый тулы ачыла.

Быел Рәсәйдә татар басма «китабы» дөнья күрүгә 290 ел тула. Ул Петр Беренченең Кавказ һәм Иран халыкларына мөрәҗәгать рәвешендә язылган (1722) «Манифест»ы. Бу мөһим вакыйга, басманың эчтәлеге Рәшит Галләм һәм Нәҗип Нәкъкаш әзерләгән материалларда яктыртылган (10 нчы сан).

* * *

Кыскасы, «Казан утлары», аның 2011 елгы саннары хакында тагын да сөйләргә, язарга мөмкин булыр иде. Чөнки моның өчен бай материал, ныклы нигез бар. Әмма шунысы ачык: журнал, кыен шартларга да карамастан, үзенең төп мәсләгенә, кыйбласына — татарга хезмәт итүгә — тугры калды, үзенең дәрәҗәсен төшермәде, милли тормышыбызның мәркәзи бер учагы булып калуын дәвам итте. Бу, әлбәттә, иң беренче чиратта, журнал хезмәткәрләренең, авторларның тырышлык нәтиҗәсе. Журнал, нигездә, татарча язылган, татар кешеләре тарафыннан иҗат ителгән, оригиналь эчтәлекле материаллар белән эш итә. Бу да бик мөһим күренеш. Киләчәктә дә «Казан утлары» татарның барыр юлларын яктыртып торсын иде!

8.01.2012